КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 ноябрь г.Казань № 1218

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче; 2018 ел, 4 май, 317 нче; 2018 ел, 27 июнь, 523 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы; 2019 ел, 4 апрель, 270 нче; 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы; 2020 ел, 26 март, 220 нче; 2020 ел, 25 май, 424 нче; 2020 ел, 26 август, 744 нче; 2020 ел, 14 октябрь, 924 нче; 2021 ел, 4 май, 306 нчы; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче, 2022 ел, 5 март, 196 нчы; 2022 ел, 9 июль, 661 нче; 2022 ел, 6 сентябрь, 964 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:
беренче абзацта «5 726,7» саннарын «6 292,9» саннарына алмаштырырга;
икенче абзацта «3 041,9» саннарын «3 163,5» саннарына алмаштырырга;
өченче абзацта «2 684,8» саннарын «3 129,4» саннарына алмаштырырга;
әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәдә:
3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:
Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07*);
Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01*);
Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән сәнәгать белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.01*);
Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән территориаль планлаштыру функциясен гамәлгә ашырганда (01.05.01*);
Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13*);
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02*);
Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән башка) функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.02*);
Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:
социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);
инвестиция эшчәнлегe өлкәсендә җайга салу (01.09*);
инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11*);
Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01*);
социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.1*);
Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.03*);
Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*).»;
3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә:

Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохитне саклау буенча төп юнәлешләрне билгеләүдә катнаша;

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең экологик үсеше өлкәсендә федераль сәясәтне гамәлгә ашыруда катнаша;

үз вәкаләтләре чикләрендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актлары проектларын законнар белән билгеләнгән тәртиптә әзерли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә, шулай ук аларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә норматив хокукый актлар, инструктив-методик документлар әзерли һәм кабул итә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары белән берлектә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, шулай ук әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре буенча башка норматив хокукый актлар әзерли һәм аларны тормышка ашыра;

Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге мәҗбүри таләпләрнең үтәлешенә төбәк дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) (федераль дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә) тотылырга тиешле булмаган объектларга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән рөхсәт документларындагы таләпләрне кертеп) гамәлгә ашыра;

әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә контроль (күзәтчелек) чараларын гамәлгә ашыру кысаларында әйләнә-тирә мохит объектларын һәм әйләнә-тирә мохиткә пычраткыч матдәләр чыгару һәм агызу чыганакларын сайлап ала, тикшерә (сыный), аларның пробаларын үлчи;

Министрлыкның Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контролен (күзәтчелеген), төбәк дәүләт геология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеген билгеләү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертә;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарны бозып гамәлгә ашырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлекне (федераль дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә) булырга тиешле объектлардан тыш) билгеләнгән тәртиптә чикләү, туктатып тору һәм (яки) тыю турында таләп белән, шулай ук табигатьне саклау законнарын үтәүне тәэмин итү максатларында билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендәге башка таләпләр белән судка мөрәҗәгать итә;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә законнарны бозу аркасында әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны каплау турында дәгъвалар бирә;

хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын икътисади бәяләүне, Татарстан Республикасы территориясен экологик паспортлаштыруны гамәлгә ашыруны оештыра;

үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге), төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) нәтиҗәсендә алынган мәгълүматны анализлый һәм гомумиләштерә;

тиешле елга Татарстан Республикасы бюджеты турында закон проектын эшләгәндә, Татарстан Республикасы бюджетын үтәүне оештыруда һәм үтәүдә катнаша;

территориаль планлаштыру документларын карауда Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә катнаша;

әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган һәм төбәк дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә) булырга тиешле объектларның төбәк дәүләт реестрын алып бара;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәү һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өлешендә Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе тарафыннан җибәрелә торган комплекслы экологик рөхсәтнамәләр алуга заявкаларны һәм аларга теркәлә торган материалларны карап тикшерүне башкара;

Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә), төбәк дәүләт геология контролендә (күзәтчелегендә) булырга тиешле II һәм III категорияләргә кертелгән объектларда хуҗалык һәм (яки) башка эшчәнлек башкаручы юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан тапшырыла торган җитештерү экология контролен оештыру турында һәм аны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисаплар кабул итүне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә), төбәк дәүләт геология контролендә (күзәтчелегендә) булырга тиешле II һәм III категорияләргә кертелгән объектларда хуҗалык һәм (яки) башка эшчәнлек башкаручы юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан тапшырыла торган әйләнә-тирә мохитне саклау чаралары планының үтәлеше турында хисаплар кабул итүне гамәлгә ашыра;

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән башкарма хакимиятнең федераль органы белән килештереп, Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохиттә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм бәяләү, һәм (яки) әйләнә-тирә мохиттә тупланган зыянны бетерү, һәм (яки) хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яки) киметү буенча башка чараларны гамәлгә ашыру, табигать мохитен саклау һәм торгызу, табигать ресурсларын рациональ файдалану һәм яңадан торгызу, экологик иминлекне тәэмин итү эшләрен оештыру чаралары планын раслый;

законнар нигезендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

3.3.3 пунктчада:

җиденче абзацта «күзәтчелегендә» сүзен «контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «күзәтчелегендә» сүзен «контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.7. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә нормага салу тармагында:

хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектлары (федераль дәүләт экология (контролендә) күзәтчелегендә булырга тиешле хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектларыннан тыш) өчен әйләнә-тирә мохиткә рөхсәт ителә торган йогынтыны нормага салу эшләрен оештыра һәм үткәрә;

тиешле таләпләр һәм нормалар федераль дәрәҗәдә билгеләнгән таләпләрдән һәм нормалардан түбәнрәк булмаган әйләнә-тирә мохит сыйфаты нормативларын билгели;

атмосфера һавасын саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органы тәкъдиме буенча атмосферага пычраткыч матдәләрне рөхсәт ителгән чыгарулар нормативларына этаплап ирешү срокларын билгели;

имин булмаган метеошартлар чорында атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруларны киметү чаралары планнарын килештерә;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә нормага салу системасын формалаштыруга һәм нәтиҗәле файдалануга юнәлдерелгән норматив хокукый актларны камилләштерү һәм үстерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

төбәк дәүләт экология контроленә (күзәтчелегенә) булырга тиешле II категориягә кертелгән объектларда хуҗалык һәм (яки) башка эшчәнлек башкаручы юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан бирелә торган әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясау турында декларацияләр кабул итүне гамәлгә ашыра.»;

3.3.8 пунктчада:

алтынчы абзацта «күзәтчелегендә» сүзен «контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацта «күзәтчелегендә» сүзен «контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «дәүләт күзәтчелегендә» сүзен «дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.9 пунктчаның алтынчы абзацында «күзәтчелеге» сүзен «контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.10 пунктчаның унынчы абзацында «(муниципаль милектәгеләрдән тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 5 март, 196 нчы карарына, 3 пунктның алтынчы абзацындагы «07.07.2014» саннарын «07.06.2014» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Бу карарның 1 пунктындагы өченче – бишенче абзацлары гамәле 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин